КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 40

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләренә һәм тәртибенә 3 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче; 2015 ел, 12 сентябрь, 669 нчы, 2017ел, 15 август, 578 нче, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләренә һәм тәртибенә 3 нче кушымтага, 1 пунктның егерме өченче абзацында «(кадрлар бүлеге башлыгы раслаган барлык битләр)» сүзләреннән соң «яисә тиешенчә таныкланган кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган (эш бирүченең булганда) электрон документ рәвешендә" сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин